**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕГОРКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЕГОРКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Егоркино ав. **КАРАР**

«13» октябрь 2025 ел № 3

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге Единение авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Егоркино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Единение авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Лунная урамындагы 1-30 йортларда яшәүче гражданнар өчен Единение авылыныж Лунная урамы 8 йорт янында 2025 елның 29 октябрендә 14 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раcларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегенең Единение авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- урамнарны яктырту җайланмасы;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында

http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Каравыл Тавы авылының мәгълүмат стендларында халык җыенын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И.Борисов